КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь г.Казань № 999

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында» 2014 ел, 29 август, 619 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында» 2014 ел, 29 август, 619 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 август, 617 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә, аны бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 29 август, 619 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 2 ноябрь, 999 нчы
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика еллык конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү максатларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Бу Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

«Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы (алга таба – мобиль кушымта) – iOS яки Android операция системалары базасында фото- яки видеохәбәрләр тапшыру өчен җайланмаларга мобиль кушымта;

мәгариф порталы – «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» порталы https://edu.tatar.ru/;

катнашучының шәхси кабинеты – мобиль кушымтадагы шәхсиләштерелгән эш киңлеге;

фото- яки видеохәбәр – модерациягә мобиль кушымта ярдәмендә кергән, Татарстан Республикасы территориясендә кирәкмәгән урында (калдыклары өчен контейнерлар куярга мәйданчык, калдыкларны вакытлыча куеп тору өчен чүплек савыты белән җиһазландырылмаган урында) җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба – калдыклар) булу турында сөйли торган сурәтне, Татарстан Республикасы территориясендә агызыла торган суларны чыганактан (торба, канализация люгы, шланг һ.б.) җир рельефына (туфракка) чыгару фактлары, шулай ук табигатьне саклау законнарын бозу фараз ителгән урынның координатлары турында сөйли торган сурәтне үз эченә алган хәбәр;

модерация – фото- яки видеохәбәрләрне карау барышында аларга алдан экспертиза һәм мониторинг үткәрү;

модератор – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына карап тикшерүгә җибәргәнгә кадәр хәбәрнамәләргә алдан экспертиза ясау өлешендә модерацияләүне гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенең Гражданнар аудио- һәм видеомөрәҗәгатьләрен эшкәртү үзәге.

1.3. Конкурсның төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын әйләнә-тирә мохитнең торышын яхшырту буенча практик эшкә җәлеп итү;

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучыларында актив тормыш позициясе тәрбияләү.

1.4. Конкурс ел саен 1 сентябрьдән 31 августка кадәр үткәрелә.

1.5. Конкурсны оештыручылар – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы.

Конкурсны оештыручылар:

Конкурсны үткәрү мәсьәләләре буенча катнашучыларга үз вакытында мәгълүмат бирә;

Конкурсны үткәрү барышы һәм аның йомгаклары турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә;

Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын әзерли һәм үткәрә;

бу Нигезләмә белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

1.6. Конкурс Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмалары арасында түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1 – 4 сыйныфлар, 5 – 8 сыйныфлар, 9 – 11 сыйныфлар категорияләрендә «Иң актив укучы»;

1 – 4 сыйныфлар, 5 – 8 сыйныфлар, 9 – 11 сыйныфлар категорияләрендә «Иң актив сыйныф»;

«Иң актив мәктәп»;

«Иң яхшы муниципаль район/шәһәр округы».

## 2. Конкурста катнашу тәртибе

2.1. Конкурста Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының мәгариф порталында һәм мобиль кушымтада теркәлгән укучылары (алга таба – катнашучы) катнашырга хокуклы.

2.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

iOS яки Android системасына яраклы җайланмага мобиль кушымта куярга;

мобиль кушымтада укучының «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» https://edu.tatar.ru/ мәгариф порталындагы исәпкә алу язмасы ярдәмендә теркәлергә;

фото- яки видеохәбәрләрне мобиль кушымта аша җибәрергә, җибәрелә торган хәбәрләр саны чикләнмәгән.

2.3. Модератор фото- яки видеохәбәрләр кергән көннән өч көн эчендә фото- яки видеохәбәрләрне Конкурста катнашуга кертү турында яки Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту хакында карар кабул итә, бу турыда укучыга Конкурста катнашучының шәхси кабинеты аша хәбәр итә.

2.4. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә, әгәр дә фото- яки видеохәбәр:

кирәкмәгән урында калдыклар өеме булуны яки агызыла торган суларны җирлек рельефына (туфракка) чыгару фактын, күздә тотыла торган бозу урыны координаталарын күрсәтмәсә;

кабаттан җибәрелгән (фотодагы- яки видеодагы сурәт үзенең күренеше, урыны һәм эшләнгән көне буенча).

2.5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы конкурста катнашуга кергән фото- яки видеохәбәрне карап тикшерә һәм мәгълүматны тикшерү өчен законнар белән кабул иткән чараларны күрә. Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча хәбәргә түбәндәге статусларның берсе бирелә:

«Бар тартылды» – хәбәрдә күрсәтелгән кирәкмәгән урында калдыклар өеме булу турындагы яки агызыла торган суларны җирлек рельефына (туфракка) чыгару факты турындагы мәгълүмат расланмаган очракта;

«Карап тикшерелде» – кирәкмәгән урында калдыклар өеме булу турындагы яки агызыла торган суларны җирлек рельефына (туфракка) чыгару факты турындагы мәгълүмат расланган һәм бозуларны бетерү өчен кирәкле чаралар үткәрелгән очракта, шулай ук бозучыларны законнар нигезендә җаваплылыкка җәлеп иткән очракта.

2.6. Кирәкмәгән урында калдыклар өеме булу турындагы яки агызыла торган суларны җирлек рельефына (туфракка) чыгару факты турындагы фото- яки видеохәбәргә «Карап тикшерелде» статусы бирелгәннән соң катнашучыга 1 балл исәпләнә. Видеохәбәрдә кирәкмәгән урында җитештерү һәм куллану калдыкларын яки агызыла торган торган суларны җирлек рельефына (туфракка) чыгару процессы күрсәтелгән очракта, видеохәбәрдә транспорт чарасы калдыкларны чыгару вакытында, траспорт чарасының маркасы һәм дәүләт номеры, әйләнә-тирә мохит күрсәтелгән булу шарты белән, катнашучыга эксперт комиссиясе карары нигезендә агымдагы ел конкурсы йомгаклары буенча кул режимында 10 балл исәпләнә.

## 3. Эксперт комиссиясе

3.1. Җиңүчеләрне билгеләү һәм Конкурска нәтиҗәләр ясау өчен, эксперт комиссиясе төзелә, аның составы ел саен 25 августка кадәр Конкурсны оештыручыларның уртак боерыгы белән раслана.

3.2. Эксперт комиссиясе экологик күзәтчелек һәм экологик белем бирү өлкәсендәге төп белгечләр арасыннан төзелә.

3.3. Эксперт комиссиясе эше, аның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, утырышлар рәвешендә үтә.

3.4. Эксперт комиссиясе эше белән аның рәисе җитәкчелек итә. Эксперт комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәие урынбасары башкара.

3.5. Эксперт комиссиясе карары эксперт комиссиясенең утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә.

3.6. Эксперт комиссиясе әгъзларының тавышлары тигез булган очракта, эксперт комиссиясе рәисе яки аның урынындагы зат тавышы хәлиткеч санала.

3.7. Эксперт комиссиясе укучыларның, сыйныфларның һәм Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының рейтингларын карап тикшерә, гомуми утырышта иң күп балл җыйган катнашучыларның фото- яки

видеохәбәрләренә экспертиза үткәрә һәм ачык тавыш бирү юлы белән һәр номинация буенча Конкурста җиңүчеләрне билгели.

3.8. Эксперт комиссиясе Конкурста катнашучылардан муниципаль район һәм шәһәр округы территориясендә калдыклар һәм җирлек рельефына (туфракка) агызыла торган суларны чыгару фактлары турында кергән фото- һәм видеохәбәрләр санына карата формалаштырылган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары рейтингларын һәм бозулары бетерелгән әлеге материалларны карап тикшерә.

3.9. Эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм барлык эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.

## 4. Конкурска йомгаклар ясау тәртибе

4.1. Конкурс үткәрелгән чорда модератор тарафыннан фото- яки видеохәбәрләрнең автоматлаштырылган мониторингы алып барыла һәм бары тик Конкурсны оештыручылар өчен генә ачык булган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары, укучылары һәм сыйныфлары рейтинглары төзелә.

4.2. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе:

«Иң актив укучы» номинациясендә – бер катнашучыдан иң күп фото- яки видеохәбәрләр саны буенча;

«Иң актив сыйныф» номинациясендә – фото- яки видеохәбәрләр җибәргән бер сыйныф укучыларының – Конкурста катнашучыларның иң күп проценты буенча;

«Иң актив мәктәп» номинациясендә – укучылары фото- яки видеохәбәрләр җибәргән гомуми белем бирү оешмасы сыйныфларының иң күп проценты буенча;

«Иң яхшы муниципаль район, шәһәр округы» номинациясендә – калдыклар һәм җир рельефына агызыла торган суларны чыгару фактлары турында карап тикшерелгән фото- һәм видеохәбәрләрнең һәм бозулары бетерелгән әлеге материалларның иң күп саны буенча.

4.3. Һәр номинация буенча җиңүчеләр һәм призлар саны бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымта нигезендә билгеләнә.

4.4. Эксперт комиссиясе Конкурска йомгакларны ел саен 20 сентябрьгә кадәр ясый.

4.5. Йомгаклар ясалганнан соң, Конкурста җиңүчеләргә тантаналы чарада бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымта нигезендә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсында җиңүчеләр өчен приз фондын бүлү

| Сыйныфлар | Номинацияләр буенча җиңүчеләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Иң актив укучы» | | «Иң актив сыйныф» | | «Иң актив мәктәп» | |
| | урын (сан) | түбәндәге суммага укучыга бүләк, 1 данәгә мең сум | урын (сан) | түбәндәге суммага сыйныфка бүләк, 1 данәгә мең сум | урын (сан) | түбәндәге суммага мәктәпкә бүләк, 1 данәгә мең сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Шәһәр гомуми белем бирү оешмалары | | | | | | |
| 1 – 4 | 1 (1 данә) | 47,0 | 1 (1 данә) | 51,0 | 1 (1 данә) | 30,0 |
| | 2 (1 данә) | 40,0 | | | | |
| | 3 (1 данә) | 33,0 | | | | |
| 5 – 8 | 1 (2 данә) | 47,0 | 1 (1 данә) | 51,0 | 1 (1 данә) | 30,0 |
| | 2 (2 данә) | 40,0 | | | | |
| | 3 (2 данә) | 33,0 | | | | |
| 9 – 11 | 1 (2 данә) | 40,0 | 1 (1 данә) | 51,0 | 1 (1 данә) | 30,0 |
| | 2 (2 данә) | 35,0 | | | | |
| | 3 (2 данә) | 33,0 | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Авыл гомуми белем бирү оешмалары | | | | | | |
| 1 – 4 | 1 (2 данә) | 47,0 | 1 (1 данә) | 51,0 | 1 (2 данә) | 30,0 |
| | 2 (2 данә) | 40,0 | | | | |
| | 3 (2 данә) | 33,0 | | | | |
| 5 – 8 | 1 (2 данә) | 47,0 | 1 (1 данә) | 51,0 | 1 (2 данә) | 30,0 |
| | 2 (2 данә) | 40,0 | | | | |
| | 3 (2 данә) | 33,0 | | | | |
| 9 – 11 | 1 (2 данә) | 40,0 | 1 (1 данә) | 51,0 | 1 (2 данә) | 30,0 |
| | 2 (2 данә) | 35,0 | | | | |
| | 3 (2 данә) | 33,0 | | | | |
| «Иң яхшы муниципаль район, шәһәр округы» номинациясе – 10,0 мең сумга 1 урын (1данә) | | | | | | |
| Призлы урыннарның гомуми саны – 49 | | | | | | |

---